# Сөйләм төре буларак хәбәри жанрлар

Сабирова Л.Р.
Казан (Идел буе) федераль университеты ассистенты,
филология фәннәре кандидаты
E-mail: lysabirova@yandex.ru

Газет укучыларының өченче буыны инде матбугат телен фәнни нигездә, җитди хезмәтләр аша күзәтә, үзләштерә ала. Газеталарыбызның теленә таләпчән, фәнни күзәтүләрне Г. Ибраһимов, Т. Алпаров кебек күренекле тел галимнәре башлавы ук әһәмияткә ия. Ә. Ишморатов, Ш. Рамазанов, В. Хаков, В. Хангилдин, Ф. Сафиуллина, С. Ибраһимов, Р. Сибәгатов, Р. Юсупов, И. Низамов, В. Гарифуллин, Х. Курбатов, И. Бәширова һ.б. хөрмәтле галимнәр татар матбугаты теленә кагылган үзенчәлекләрне ачуга саллы өлеш кертә килделәр.

Баштагы хезмәтләрдә матбугат теле грамматика кагыйдәләренә, әдәби нормаларга туры килү-килмәү яссылыгында тикшерелгән. 80-90 нчы елларда матбугат телен өйрәнү  функциональ-стилистик юнәлештә ныклап торып аяк басты, ягъни матбугатны тел куллануның мөстәкыйль бер системасы буларак анализлау методикасы эшләнеп, шул юнәлештә тәҗрибә туплана башлады. Гомуммән дә, соңгы елларда тел гыйлеме, телнең төзелеш-структурасын өйрәнү белән бер үк вакытта телне куллану мәсьәләләрен, ягъни сөйләм оештыру өлкәсендә дә җитди игътибар бирә. Нәтиҗәдә сөйләмият фәне ныклап аякка басып, тел фәненнән башка чыгу хәленә килде (профессор И.М. Низамов башлап җибәрүчеләрдән).

Күренә ки, матбугат сөйләме бүген гамәли яшәвебездә дә, фәнни өйрәнү чарасы буларак иҗтимагый бер күренеш булып җитлеккән. Бу – объектив, табигый хәл. Сөйләм гомуммилли, гомумкуллану категориясе булса да, ул, иҗтимагый фикерләү төрләренә карап, сөйләм мотивларының (иясе, адресаты, нияте, шарты һ.б.) охшаш-үзгәлекләренә карап, аерымлана (дифференциацияләнә) [1, 69 б.].

Газета-журналларда басылган, радио һәм телевидение аша яңгыраган һәрбер әсәр билгеле бер жанр кысаларында иҗат ителә. Аның эчтәлеге дә, формасы да шушы жанр таләпләре нигезендә оеша [2, 3 б.]. Журналистика фәнендә жанрларны сөйләм категориясе буларак тикшерүләр юк дәрәҗәдә. Аерып карасаң, бу өлкәдә профессор И.М. Низамовның хезмәтләре зур хөрмәткә лаек. Сөйләм категориясе буларак жанр, чыннан да, катлаулы, үзенчәлекле күренеш. Үзенчәлеге аның берьюлы берничә системага мөнәсәбәтле булуында. Беренчесе, һәм ул нигез система – мотивларга нигезләнгән конкрет сөйләм. Конкрет сөйләм диахроник планда кабатлана килеп, типикланырга тиеш. Бу үзенә бер система. Өченчесе – эчтәлек белән форма бердәмлеген тәшкил иткән закончалык[3, 115 б.]. Чынлап та, иҗат процессында журналист аерым жанр закончалыклары, жанрның чикләре турында уйламаска да мөмкин. Ләкин ул ирексездән алда иҗат итүчеләр туплаган тәҗрибәгә таянырга мәҗбүр. Нинди генә матбугат органында эшләмәсен, нинди генә темага язмасын – хәбәри жанрга һәр журналист мөрәҗәгать итә. Хәбәри (информацион) төркемгә керүче хәбәр, хисап, репортаж һәм интервью жанрларының төп функциясе – иҗтимагый әһәмияткә ия булган яңалыкны укучыга оператив хәбәр итњ. Оперативлык үз чиратында хәбәри жанрлар өчен характерлы булган тагын бер уртак сыйфатны билгели: материалларның күләме җыйнак [2, 7 б.]. Хәбәрнең дә төрләре берничә: хроника-хәбәр, аңлатмалы-хәбәр, тойгылы хәбәр. Бу жанр кысаларына хат-хәбәрне дә кертергђ була.

Жанрның асылында тел чараларының һәм шуларны сөйләм рәвешенә китереп, адресатка җиткерү чараларының бердәмлеге, эчтәлек һәм форма сыйфатлары ята. Жанр таләбен үтәү ул сөйләмеңне мотивларга ярашлы итеп оештырыр өчен материал җию, сайлау, анализлау, нәтиҗә-йомгак ясый белү дигән сүз. Димәк, жанрларның нигезендә мотивлар ята:

а) *Сөйләм иясенә* бәйле рәвештә: күпчелек язмалар хәбәри жанр булып типиклашуы турыдан-туры авторга (аны язган журналистның белеме, холкы,

табигатенә) бәйле. Журналист әсәре өстендә эшләгәндә фактка нигезләнергә кирәк. Ә фактны шулай ук төрле кеше төрлечә күрә, төрлечә аның белән эш итә.

б) *Сөйләм адресатына* бәйле рәвештә: хәбәр, хисап, репортаж яисә интервью укучыга барып җитсен өчен, журналист, әлбәттә, адрсесатны ачык күз алдына китереп иҗат итәргә тиеш. Балага атап язган материал башкалар өчен иҗат иткән хәбәри жанрдан бик нык аерыла бит.

в) *Сөйләм ниятен исә,* жанр барлыкка килү өчен беренче этәргеч дип санарга кирәктер. Жанр өчен сөйләм нияте ул шәхеснең фактка, чынбарлыкка мөнәсәбәте. Безнең хөрмәтле галимебез Р.М. Нуриллина жанрлар функциягә карап барлыкка килә дигән нәтиҗә дә чыгарган.

г) *Сөйләм шартының* жанр формалаштыруда зур урын тотуы шулай ук бәхәссез. Мәсәлән, жанрга журнал бер төрле таләп куйса, газета икенче таләп куя. Тасвирлау бурычын үтәүгә элек башлыча хикәят, юльязма, календарь жанрлар җигелгән булса, матбугат барлыкка килгәч, бу бурычны үтәүгә бөтен бер тасвири жанрлар алынды [3, 117 б.].

Жанрны сөйләм мотивларына бәйләп күзәтү, анализлау кирәк, чөнки жанр, без караган хәбәри жанрлар да, гел хәрәкәттә. Әйтик, партияләр хакимияте вакытында дөреслекне чагылдыру чарасы булган репортаж жанры бетү хәленә килгән иде, ә демократиягә юл ачыла башлаган елларда матбугат монологик формадан диологик формага күчү юнәлешен алгач, аның укучы белән ихлас аралашу ихтыяҗы көчәйгәч, жанрларның да үзгәрүе сизелә башлады. Аерым алганда интервью активлашты, төрләре ишәйде. Техник алгарыш заманы үз кануннарын булдыра, жанрлар синтезлаша, яңа төрләре барлыкка килә, әмма жанрларның асыл сыйфатлары үзгәрми.

Хроника хәбәрнең, мәсәлән, тел үзенчәлекләре номинатив берәмлекләрдән, терминнардан тора. Анда экспрессиягә, ягъни хис-кичерешләр белдерү сәләтенә

ия булган лексика, эмоциональ тәгъбир һәм әйләнмәләр, тел сурәтләү чаралары очрамый диярлек. Чөнки жанрның бу төрендә автор бәясе дә, аның уй хисләре, фикерләре дә бик аз чагыла.

Тамашачы вакыйганы, фактны дөрес аңласын, аңа тиешле бәя бирә алсын өчен журналистка еш кына аның сәбәпләрен ачып бирергә, аның әһәмиятен раслаучы өстәмә дәлилләр китерергә, хәбәр ителә торган вакыйга яки фактның аерым детальләренә киңрәк тукталырга туры килә. Моның өчен иң кулай жанр – аңлатмалы хәбәр. “Аңлатмалы хәбәрдә рәсмилек ул кадәр көчле булмый. Шулай да китерелгән фактны аңлатып, бәяләп бирү логик эзлеклелек белән тыгыз фикерле таныш сүзләр, әйләнмәләр белән булырга тиеш” – дип яза тел белгече И.М. Низамов [4, 14 б.]. Интервьюда исә, интервью бирүче фактка карата субъектив карашларын, шатлык, нәфрәт, аңлап җитмәүчәнлеген яисә хуплау хисләрен белдерә.

Хисап күбрәк җыелыш, киңәшмә, конференция, пресс-конференция һәм башка шундый вакыйгаларны сурәтли. Хисап жанрында әзерләнгән текстта В.З. Гарифуллин ике сөйләм иясен аерып карарга мөмкин дип яза [5, 23 б.]. Беренчесе – вакыйга турында сөйләүче, икенчесе вакыйга эчендә сөйләүче. Хисап жанрында *-ган-гән, -кан-кән* кушымчалары белән ясалган нәтиҗәле үткән заман, ягъни сөйләм моментына эш тәмамланган һәм нәтиҗәсе хәзерге заманда дәвам итүче фигыль формасы өстенлек итә.

“Репортаж язганда теге яки бу вакыйга турында коры сөйләү белән генә чикләнергә ярамый. Күзәтүчәнлек, кызыклы детальләр таба белү, шулардан фикер-нәтиҗә чыгару һәм әлеге фикер-нәтиҗәне сурәт аша гәүдәләндерү, хис-тойгы белән сугара алу сәләте дә автор өчен бик кирәк”, – дип язган безнең хөрмәтле укытучыбыз, журналистика өлкәсенә күп кенә хезмәтләр багышлаган Ф.И. Әгъзамов [6, 15 б.].

Хәбәри жанрда сөйләм үзенчәлекләрен барлау – үзе бер махсус фәнни

сөйләшү-өйрәнү темасы. Аны әле төпле өйрәнәсе, гомумиләштерәсе бар. Бу телне куллану даирәсен баету өчен, журналистларга практикада куллану өчен кирәк булачак.

**Әдәбият**


1. *Низамов И.М.* Татар социалингвистикасы. Казан: В, И,. Ульянов-Ленин исемендәге дәүләт университеты нәшрияте, 2006. 152 б.
2. *Гарифуллин В.З.* Вакытлы матбугатта жанрлар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007. 120 б.
3. *Низамов И.М.* Жанр ул – сөйләм категориясе // Тонус. 1996. №1. Б. 112 – 123.
4. *Низамов И.М.* Матбугатның тәэсирле сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 144 б.
5. *Гарифуллин В.З*. Газета текстының төзелеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 104 б.
6. *Әгъзамов Ф.И.* Репортаж // Ялкын. 1978. № 6. 14 – 16 б.